**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.06.2022 **Чирмешән авылы** **№187**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Урынны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану мәсьәләләрен карау буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2021 елның 13 гыйнварындагы 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары нигезендә «Урынны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставына таянып, кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә **КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Урынны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану мәсьәләләрен карау буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2021 елның 13 гыйнварындагы 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә «Торак кодексының 36 статьясындагы 1 өлешенең 1-3 пунктларында күрсәтелгән мөлкәтне үз эченә алган ике һәм аннан күбрәк фатирдан торган бина күпфатирлы йорт дип таныла. Күпфатирлы йорт шулай ук мондый күп фатирлы йортның аерылгысыз

конструктив өлеше булып торган, аерым милекчеләренә караган торак булмаган биналарны һәм (яки) машина-урыннарын үз эченә алырга мөмкин».

2. 5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә «Торак бинаның яшәү өчен яраклылыгы (яраксызлыгы) һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә дип тану турындагы мәсьәләне карау өчен мөрәҗәгать итүче торак урыны урнашкан урын буенча комиссиягә түбәндәге документларны тапшыра:

а) урынны торак бина яки торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм (яки) күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында гариза;

б) Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында хокук теркәлмәгән торак бинага хокук билгели торган документлар күчермәләре;

в) аны алга таба торак урыны дип тану өчен торак булмаган бинага карата - торак булмаган бинаны реконструкцияләү проекты;

г) күпфатирлы йортны тикшерүне үткәргән махсуслаштырылган оешма бәяләмәсе - күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы мәсьәләне кую очрагында;

д) торак урынның киртәләп торучы һәм йөртүче конструкцияләре элементларын тикшерү нәтиҗәләре буенча махсуслаштырылган оешма бәяләмәсе – әгәр Хөкүмәтнең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган «Урынны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында» нигезләмәнең 44 пунктындагы өченче абзацы нигезендә мондый бәяләмәне бирү торак урынын әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килә (туры килми) дип тану турында карар кабул итү өчен кирәкле булып торса;

е) яшәү шартлары канәгатьләндерерлек булмавына гариза, хатлар, шикаятьләр - мөрәҗәгать итүче теләгәнчә.

Мөрәҗәгать итүче гариза һәм аңа кушып бирелә торган документларны кәгазьдә шәхсән яисә почта аша тапшыру турында хәбәрнамә белән йә "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы" федераль дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - бердәм портал), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталын (булганда) кулланып яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша электрон документлар рәвешендә тапшырырга хокуклы.

Электрон документ рәвешендә бирелә торган гаризага мөрәҗәгать итүче гади электрон имза белән кул куя, ә аңа кушып бирелә торган электрон документлар әлеге документларны тапшырган органнарның (оешмаларның)

вазыйфаи затлары тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән (әгәр Россия Федерациясе законнары белән мондый документларга имза салу өчен электрон имзаның башка төре билгеләнмәгән булса) имзаланырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүче комиссиягә әлеге Нигезләмәнең 5.4 пунктында күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы.

Комиссия эш барышында нәтиҗәләре элегрәк Комиссия каравына тапшырылган документларга теркәлә торган өстәмә тикшерүләр һәм сынаулар билгеләргә хокуклы».

3. 5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә «Эш нәтиҗәләре буенча комиссия биналарны һәм күпфатирлы йортларны әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләү турында түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

бинаның торак урынына куела торган таләпләргә һәм аның яшәү өчен яраклылыгына туры килүе турында;

торак бинаны эксплуатацияләү процессында югалган характеристикаларны әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры китерү максатыннан капиталь ремонт, реконструкция яки яңадан планлаштырылырга (кирәк булганда, техник-икътисадый нигезләү белән) тиешле дип тану өчен нигезләрне ачыклау турында;

бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану өчен нигезләрне ачыклау турында;

торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану өчен нигезләрнең булмавы турында;

күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм реконструкцияләнергә тиеш дип тану өчен нигезләрне ачыклау турында;

Комиссия карар кабул итәргә хокуклы (кворум бар), әгәр комиссия утырышында аның әгъзаларының гомуми санының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, шул исәптән дәүләт күзәтчелеге (контроль) органнарының, архитектура, шәһәр төзелеше органнарының һәм тиешле оешмаларның барлык вәкилләре, комиссия составына кертелгән экспертлар катнаша.

Карар комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм карар кабул итүнең тиешле нигезләрен күрсәтеп, 3 нөсхәдә бәяләмә рәвешендә рәсмиләштерелә. Әгәр карар кабул иткәндә "өчен" һәм "каршы" тавышлары саны тигез булса, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора. Кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта, комиссия әгъзалары үзләренең аерым фикерен язмача белдерергә һәм аны бәяләмәгә куярга хокуклы.

Әлеге Нигезләмәнең 5.7 пунктындагы тугызынчы абзацында күрсәтелгән бәяләмәнең ике нөсхәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карарының 7 пунктындагы җиденче абзацында каралган карарны алга таба кабул итү һәм тиешле бина яки күпфатирлы йорт урнашкан урын буенча мөрәҗәгать итүчегә һәм (яисә) дәүләт торак күзәтчелеге (муниципаль торак контроле) органына юллау өчен комиссия тарафыннан тиешле федераль башкарма хакимият органына, Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органына, җирле үзидарә органына 3 көнлек срокта җибәрелә.

Бинаны тикшергән очракта комиссия 3 нөсхәдә 2 нче кушымта нигезендә бинаны тикшерү акты төзи. РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карарының 7 пунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән затларның тикшерүдә катнашуы мәҗбүри булып тора, әгәр алар комиссия составына кертелгән булса.

Алынган бәяләмә нигезендә тиешле федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы, җирле үзидарә органы, бәяләмә алынганнан соң 30 календарь көн эчендә, ә гадәттән тыш хәл аркасында зыян күргән торак урыннарны тикшерү очрагында, - бәяләмә алынганнан соң 10 календарь көн эчендә, анда билгеләнгән тәртиптә РФ Хөкүмәтенең 28.01.2006 ел, №47 карарының 7 пунктындагы җиденче абзацында каралган карарны кабул итә, һәм йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану очрагында, бинаны алга таба файдалануны, физик һәм юридик затларны күчерү срокларын күрсәтеп, яки ремонт-торгызу эшләре үткәрү кирәклеген тану турында күрсәтмә чыгара.

Күпфатирлы йорт авария хәлендә дип танылган һәм сүтелергә тиешле дип табылган очракта, торак биналарны найм һәм арендалау шартнамәләре законнар нигезендә өзелә.

Яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыннарына килешүләр шартнамәнең теләсә кайсы ягы таләбе буенча закон нигезендә суд тәртибендә өзелергә мөмкин»

4. 6.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә «Бакча йортын торак йорт яисә торак йортны бакча йорты дип танудан баш тарту турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

а) мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 6.2 пунктындагы "а" һәм (яки) "в" пунктчаларында каралган документларны тапшырмау;

б) җирле үзидарәнең вәкаләтле органына мөрәҗәгать итүче булмаган затның бакча йортына яки торак йортка милекче хокукы турында Күчемсез милекнең дердәм дәүләт реестрындагы белешмәләр керү;

в) җирле үзидарәнең вәкаләтле органына, әлеге Нигезләмәнең 6.2 пунктындагы "б" пунктчасында каралган хокук билгели торган документ яки мондый документның нотариаль расланган күчермәсе мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмаса, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында бакча йортына яки торак йортка теркәлгән хокуклар турында белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә керү. Җирле үзидарәнең вәкаләтле органы Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында бакча йортына яки торак йортка теркәлгән хокуклар турында белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә алганнан соң, бакча йортын торак йорты яки торак йортны бакча йорты дип танудан баш тарту күрсәтелгән нигез буенча рөхсәт ителә, әгәр мөрәҗәгать итүчегә мондый хәбәрнамәне алу турында гаризада күрсәтелгән ысул белән хәбәр ителсә, мөрәҗәгать итүчегә әлеге Нигезләмәнең 6.2 пунктындагы "б" пунктчасында каралган хокук билгеләүче документны яисә мондый документның нотариаль расланган күчермәсен күрсәтергә тәкъдим ителсә һәм мөрәҗәгать итүчедән мондый документ яки мондый күчермә хокук билгели торган документны тапшыру турында хәбәрнамә җибәргәннән соң 15 календарь көн эчендә тапшырылмаса;

г) мөрәҗәгать итүче әлеге Нигезләмәнең 6.2 пунктындагы "г" пунктчасында каралган документны, әгәр бакча йорты яки торак йорт өченче затларның хокуклары белән йөкләнгән булса, тапшырмау;

д) Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалану төрләре, мондый урнаштыруны күздә тотмый торган җир кишәрлегендә бакча йортын яки торак йортны урнаштыру;

е) торак йортны мөрәҗәгать итүче яисә башка зат тарафыннан даими яшәү урыны буларак файдалану (торак йортны бакча йорты дип тану турында гаризаны караганда);

ж) су басу зонасы чикләрендә урнашкан җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыру (бакча йортын торак йорт дип тану турында гаризаны караганда) ».

5. Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру бүлегенә өч эш көне эчендә 1 пунктта расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru), шулай ук муниципаль берәмлекләр порталында, Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырганнан соң үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе И.Н.Шәйдуллин